РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НОВОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«16» июль 2018 ел № 53-3

ТР Буа муниципаль районы
Яңа Тинчәле авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге территориясендә
төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

06.10.2003 елгы 31-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, һәм төзекләндерү объектларын һәм гомумән ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен чисталыкта һәм тәртиптә тотуга карата бердәм таләпләр булдыру максатында, ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 14.11.2017 елгы 41-2 номерлы «ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы карары белән расланган ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 пунктның 5 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«территорияне төзекләндерү – гражданнарның яшәү шартларының комфортлылыгын тәэмин итүгә һәм аны күтәрүгә, территориянең санитар һәм эстетик торышын тотуга һәм яхшыртуга юнәлдерелгән муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү буенча, аларны үткәрү тәртибе һәм ешлыгы, шулай ук территорияләрне төзекләндерү элементларын прекtлаштыру һәм урнаштыру буенча чаралар исемлеге;»;

1.2. 6 пунктның 30 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«стационар булмаган сәүдә объекты - инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу-тоташмау (технологик тоташу) белән бәйсез рәвештә, җир кишәрлеге белән ныклап бәйле булмаган вакытлыча корылма яки вакытлыча конструкциядән гыйбарәт сәүдә объекты, шул исәптән күчмә корылма;»;

1.3. 10 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«10. 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләре үткәрүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешмалар тарафыннан тормышка ашырыла»;

1.4. 13 пунктның 2 пункт астын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) гомуми кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләрнең чикләрендә – вәкаләтле орган яки 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эшләрне җитештерүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешма.»;

1.5. 16 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«16. Җәмәгать транспортын көтү павильоннарын тоту һәм җыештыру 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешма тарафынан тәэмин ителә.»;

1.6. 51 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«51. Муниципаль юлларны тоту 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешма тарафыннан, яки юлларның башка хуҗалары (андыйлар булса) үз көчләре яки подрядчы оешмалар тарафыннан тормышка ашырыла.»;

1.7. 81 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«81. Тышкы яктыртуның бердәм системасына тоташтырылган урам һәм йорт алды яктыртуын тоту һәм ремонтлауны вәкаләтле орган яки 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешма, яки баланс чикләре нигезендә Челтәр компаниясе тормышка ашыра.»;

1.8. 90 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«90. Кече архитектура формаларын тоту җир кишәрлекләренең хокук хуҗалары тарафынан аларга бирелгән җир кишәрлекләре чикләрендә, гомуми кулланыштагы территорияләрдә тормышка ашырыла– вәкаләтле органның 05.04.2013 елгы 44-ФЗ номерлы «Товарлар алу, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә муниципаль заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурсны җиңгән махсуслашкан оешма белән төзелгән килешүе нигезендә тәэмин ителә.»;

1.9. 109.11 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«109.11. Транспорт чараларының һәр тукалышында, шул исәптән социаль, инженер 1әм транспорт инфраструктуралары (торак, җәмәгать һәм производство биналары, төзелешләре һәм корылмалары, физкультура-сопрт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашканнарын да кертеп), ял итү урыннары объектлары тирәсендә РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән транспорт чаралары белән идарә итүче I, II төркем инвалидлары, шулай ук III төркем инвалидларга һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны ташучы транспорт чараларына түләүсез парковка өчен 10 проценттан да ким булмаган (әмма бер урыннан да ким түгел) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән транспорт чараларында "Инвалид" тану билгесе куелган булырга тиеш. Индивидуаль кулланылыштагы "Инвалид" тану билгесен бирү тәртибен башкару хакимиятенең федераль органы РФ Хөкүмәтенең вәкаләтле вәкиле билгели. Парковка өчен күрсәтелгән урыннарны башка транспорт чаралары алырга тиеш түгел;»;

1.10. Кагыйдәләр тексты:

түбәндәге редакциядә X бүлекне өстәргә:

**«X. Территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар, гавәми тыңлаулар.**

**213.** Кешенең тормыш итүгә уңайлы шартлар хокукын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатында, федераль законда каралган очракларны исәпкә алмаганда, Кагыйдәләр проекты, әлеге Кагыйдәләр нигезендә үзгәрешләр кертү каралган проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавәми тыңлаулар үткәрелә.

**214.** Кагыйдәләр проекты, әлеге Кагыйдәләр нигезендә үзгәрешләр кертү каралган проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавәми тыңлауларда катнашучылар – Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар,җир кишәрлекләре һәм (яки) андагы капиталь төзелеш объектлары Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясе чикләрендә урнашкан хокуклы хуҗалар, шулай ук капиталь төзелешнең күрсәтелгән объектларының өлеше булган биналарның хокуклы хуҗалары.

**215.** Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү прцедурасы түбәндәге этаплардан тора:

1) иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр бирү;

2) иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проектны һәм аңа кагылышлы информацион материалларны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, http://buinsk.tatarstan.ru. (алга таба әлеге маддәдә – рәсми сайт) адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында ТР Буа муниципаль районының рәсми сайтында, яки https://uslugi.tatarstan.ru ТР дәүләт һәм муниципаль дәүләтләр порталында (алга таба - информацион система) урнаштыру һәм экспозиция яки мондый проект экспозицияләрен ачу;

3) иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле экспозиция яки проект экспозицияләре үткәрү;

4) иҗтимагый фикер алышуларның беркетмәсен әзерләү һәм язу;

5) иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында йомгак әзерләү һәм аны бастыру.

**216.** Гавәми тыңлаулар үткәрү прцедурасы түбәндәге этаплардан тора:

1) гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр бирү;

2) гавәми тыңлаулар каралырга тиешле проектны һәм аңа кагылышлы информацион материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм экспозиция яки мондый проект экспозицияләрен ачу;

3) гавәми тыңлауларда каралырга тиешле экспозиция яки проект экспозицияләре үткәрү;

4) җыелыш яки гавәми тыңлауларда катнашучылар җыелышы үткәрү

5) гавәми тыңлауларның беркетмәсен әзерләү һәм язу;

6) гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгак әзерләү һәм аны бастыру.

**217.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр бирү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат, һәм бу проектка кагылышлы информацион материаллар;

2) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны үткәрү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат;

3) иҗтимагый фикер алышуларда һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле экспозиция яки проект экспозицияләре ачу урыны, датасы турында мәгълүмат, экспозиция яки проект экспозицияләре үткәрү вакыты, күрсәтелгән экспозиция яки эспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр урында мәгълүмат;

4) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар тарафыннан тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат.

**218.** Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрдә шулай ук иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект һәм аңа кагылышлы информацион материаллар урнаштырылачак рәсми сайт, яки мондый проект һәм аңа кагылышлы информацион материаллар урнаштырылачак һәм алар ярдәмендә иҗтимагый фикер алышулар уздырылачак информацион системалар турында мәгълүмат булырга тиеш. Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрдә шулай ук иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект һәм аңа кагылышлы информацион материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында, җыелыш яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат булырга тиеш.

**219.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр: бирү

1) рәсми сайтта яки иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проектның информацион системаларында, шулай ук, әгәр муниципаль хокук актларында каралган булса, башка масса мәгълүмат чараларында урнаштыру көненнән җиде көн кала муниципаль хокук актлары, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру тәртибендә басылырга тиеш;

2) җирле үзидарә органының иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны үткәрү өчен вәкаләтле бина тирәсендә җиһазландырылган иформацион стендларда, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучыларга күрсәтелгән мәгълүмат барып җитүне тәэмин итүче башка ысуллар белән әзерләнгән мондый проектка карата, гражданнарның күпләп җыелу урыннарында һәм Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә урнашкан башка урыннарда таратылырга тиеш.

**220.** Урнаштыру дәвере эчендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм бу проектка кагылышлы информацион материалларның әлеге Кагыйдәләренең 215 пункт 2 пункт асты һәм 216 пункт 2 пункт асты нигезендә экспозиция яки мондый прект экспозицияләре үткәрелә. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект турында информацион материаллар таратылырга тиеш. Экспозициягә килүчеләргә консультацияне җирле үзидарә органы яки аның тарафыннан булдырылган коллегиаль киңәшмә органының (алга таба - иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны үткәрүгә вәкаләтле вәкил һәм (яки) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проектны эшләүче бирә.

**221.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм бу проектка кагылышлы информацион материалларның һәм экспозиция яки мондый проект экспозицияләре үткәрү турында әлеге маддәне 215 пункт 2 пункт асты һәм 216 пункт 2 пункт асты нигезендә урнаштырылган дәверендә, әлеге Кагыйдәләрнең 223 пункты нигезендә идентификация үткән иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт яки информацион системалар (иҗтимагый фикер алышулар үткәргән очракта);

2) җыелыш яки гавәми тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән рәвештә (гавәми тыңлаулар үткәргән очракта);

3) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә;

4) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язып.

**222.** Әлеге Кагыйдәләрнең 221 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләр теркәлергә, шулай ук иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручылар тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш, әлеге Кагыйдәләрнең 226 пунктында каралган очракны исәпкә алмаганда.

**223.** **И**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар, идентификация максатында, физик затлар өчен - үзләре турында мәгълүмат бирергә тиеш (фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта), туу датасы, тору урыны (теркәлү) адресы; юридик затлар өчен - исем, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адрес – бу мәгълүматларны раслаучы документлар да бирелергә тиеш. **Җ**ир кишәрлекләре һәм (яки) анда урнашкан капиталь төзелеш объектлары һәм (яки) капиталь төзелешнең күрсәтелгән объектлары биналарының хокуклы хуҗалары булган иҗтимагый фикер алышулар яки гавәми тыңлауларда катнашучылар да күчемсез милек Бердәм дәүләт реестрыннан мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, капиталь төзелешнең күрсәтелгән объектларының өлеше булган биналар турында мәгълүмат һәм мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, капиталь төзелешнең күрсәтелгән объектларының өлеше булган биналарга хокуклы булуларын раслаучы яки танучы документлар бирәләр.

**224.** Әлеге Кагыйдәләрнең 223 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар турында мәгълүматны (физик затлар өчен - фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта), туу датасы, тору урыны (теркәлү) адресы; юридик затлар өчен - исем, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адрес) раслаучы документлар да бирелергә тиеш, әгәр бу затлар тарафыннан **и**җтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проектка карата рәсми сайт яки информацион системалар аша иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелсә (бу мәгълүматлар рәсми сайтта яки информацион системаларда булган очракта). Әлеге маддәнең 12 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматларны раслау өчен идентификация и аутентификациянең бердәм системасы кулланылырга мөмкин.

**225.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучыларның персональ мәгълүматларын эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге152-ФЗ номерлы «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль законда күрсәтелгән таләпләрне истә тотып башкарыла.

**226.** Әлеге маддәнең 10 өлеше нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлар бирү факты ачылган очракта, каралмый.

**227.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы тарафыннан **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучыларның барысын да (шул исәптән **и**җтимагый фикер алышуларны үткәргәндә рәсми сайтка, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәкләрдә һәм (яки) җирле үзидарә органнарының биналарында информацион системаларга кертү юлы белән дә) тигез итеп кертүне тәэмин итә.

**228.** Рәсми сайт һәм (яки) информацион системалар түбәндәге мөмкинлекләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) **и**җтимагый фикер алышуларда катнашучылар тарафыннан **р**әсми сайтта һәм (яки) информацион системаларда алар керткән тәкъдимнәр һәм кисәтүләрне яктыртуның тулылыгы һәм дөреслеген тикшерү;

2) **и**җтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре, **и**җтимагый фикер алышуларда катнашучылар саны турында мәгълүмат бирү.

**229.** Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар беркетмәсен әзерли, анда:

1) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар беркетмәсен төзү датасы;

2) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы турында мәгълүмат;

3) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында басылган хәбәр үз эченә мәгълүматны, басылу датасын һәм чыганакны ала;

4) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылардан кергән тәкъдимнәр һәм кисәтүләрнең алыну вакыты, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар үткәрелә торган территория чикләре турында мәгълүмат;

5) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучыларның барлык тәкъдимнәре һәм кисәтүләре, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучы һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар үткәрелә торган территория чикләрендә даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда башка катнашучыларның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре дип аерып күрсәтелгән рәвештә.

**230. И**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларның беркетмәсенә **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар проектын каралуында катнашучыларның үз эченә катнашучылар турында мәгълүматны (физик затлар өчен - фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта), туу датасы, тору урыны (теркәлү) адресы; юридик затлар өчен - исем, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адрес) алган исемлеге куела.

**231**. Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралган проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр керткән иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучы үз эченә бу катнашучы тарафыннан кертелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләрне алган беркетмә выпискасын алырга хокуклы.

**232**. Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар беркетмәсе нигезендә **и**җтимагый фикер алышуларны оештыручы **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау әзерли.

**233**. **И**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклауда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау язу датасы;

2) **и**җтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралган проект исеме, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар саны турында мәгълүмат;

3) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау нигезендә әзерләнгән иҗтимагый фикер алышулар яки гавәми тыңлаулар беркетмәсе реквизитлары;

4) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучыларның барлык тәкъдимнәре һәм кисәтүләре, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучы һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар үткәрелә торган территория чикләрендә даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда башка катнашучыларның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре. Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда берничә катнашучының бертөрле тәкъдим һәм кисәтүләре кертелгән очракта, андый тәкъдим һәм кисәтүләр гомумиләштерелә;

5) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручының иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләрне исәптә тотуның максатка ярашлы яки максатка ярашлы түгеллеге турында дәлилле тәкъдимнәр һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгак.

**234**. Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә бастырыла, һәм рәсми сайтта һәм (яки) информацион системаларда урнаштырыла.

**235**. Әлеге Кагыйдәләр белән РФ Шәһәр төзелеше Кодексы нигезләмәләре нигезендә түбәндәгеләр билгеләнә:

1) проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе;

2) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны оештыручы;

3) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларны үткүрү вакыты;

4) рәсми сайт һәм (яки) информацион системалар;

5) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштырыласы информацион стендларга карата таләпләр;

6) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр итү формасы, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар беркетмәсен әзерләү тәртибе һәм формасы, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгак әзерләү тәртибе һәм формасы;

7) иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү тәртибе, шулай ук иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибе.

**236**. Төзекләндерү кагыйдәләре проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар үткәрү вакыты иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар башлану турында хәбәр басылган көннән иҗтимагый фикер алышулар һәм гавәми тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау басылган көнгә кадәр муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокук актлары белән билгеләнә, һәм бер айдан да ким һәм өч айдан да артмаска тиеш.»

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак.

3. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Яңа Тинчәле авыл җирлеге Башлыгы Р.К. Мадышев